РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУСЛЮМОВСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕТАБЫНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ

ТҮБӘН ТАБЫН
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Юрид.адрес: 423977, РФ,РТ,Муслюмовский район, с. Нижний Табын, ул. Молодёжная, 10
Факт.адрес: 423977, РФ, РТ, Муслюмовский район, с. Верхний Табын, ул. Тукая, 19Б
Тел./факс: 8-85556-32874 / бух. 2-58-66 Элект. адрес: Ntab.Mus@tatar.ru
ИНН 1629003865, КПП 162901001, ОГРН 1061687001166, ОКТМО 92642450

**Югары Табын авылы** **«26» гыйнвар, 2022 ел**

**КАРАР № 03-05**

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Түбән Табын авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары турында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карары, «2022 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе күләмен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә, Мөслим муниципаль районының Түбән Табын авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1.2022 елның 1 февраленнән Мөслим муниципаль районының Түбән Табын авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен, 1 нче һәм 2 нче кушымта нигезендә, 6964,68 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2.Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Түбән Табын авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольда тотуны үз өстемә алам.

**Башкарма комитеты житәкчесе** **Р.Ш. Кыяметдинов**

Мөслим муниципаль районы
Түбән Табын авыл җирлеге
Башкарма комитеты
2022 елның 26 нчы гыйнвар
03-05 нче номерлы карарына
1 нче кушымта

**2022 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районыныңТүбән Табын авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенең бәясе**

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе *(сум)* |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү. | 0,00 |
| 2. Җирләү өчен табут һәм башка кирәк-яраклар бирү һәм китерү. | 3550,51 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (гәүдә калдыкларын) зиратка илтү. | 1368,39 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү). | 2045,78 |
| **Барлыгы** | **6964,68** |

Мөслим муниципаль районы
Түбән Табын авыл җирлеге
Башкарма комитеты
2022 елның 26 нчы гыйнвар
03-05 нче номерлы карарына
2 нче кушымта

**2022 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Түбән Табын авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенең бәясе**

| **Хезмәт күрсәтү исеме** | **Хезмәт күрсәтү бәясе *(сум)*** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү. | 0,00 |
| 2. Кәфенләү. | 1079,31 |
| 3. Җирләү өчен табут һәм башка кирәк-яраклар бирү һәм китерү. | 2501,6 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка илтү. | 1393 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү). | 1990,77 |
| **Барлыгы** | **6964,68** |